**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы**
**Калмия авыл җирлеге составына керүче**
**Кырныш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

14 октябрь 2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 14 октябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:
«Калмия авыл җирлегенең Кырныш авылы территориясендә 2024 елда балигъ булган, Калмия авыл җирлегенең Кырныш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (Биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (Ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме:

- юллар ремонтлау.

“ӘЙЕ” “ЮК”.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 175 кеше катнашучы кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 89 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 89 кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:
1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегенең Кырныш авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.
2. «Калмия авыл җирлегенең Кырныш авылы территориясендә 2024 елда балигъ булган, Калмия авыл җирлегенең Кырныш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 1000 (Бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (Биш йөз) сум күләмендә

билгеләргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Центральная урамында һәм киселешләрдә юл төзелеше буенча эшләр башкару, вак таш сатып алу, махсус техника хезмәтләре» мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегенең Кырныш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегенең Кырныш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Калмия авыл җирлеге Башлыгы Р.Ә.Гарипов